КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 апрель г.Казань № 382

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 10 декабрь, 932 нче; 2017 ел, 14 ноябрь, 873 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1133 нче; 2020 ел, 30 июль, 636 нчы; 2020 ел, 20 ноябрь, 1035 нче; 2021 ел, 26 апрель, 286 нчы, 2021 ел, 20 июль, 606 нчы, 2022 ел, 28 гынвар, 66 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

дүртенче абзацта «гражданнарга» сүзен «гаиләләргә (ялгыз яшәүче гражданнарга)» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән гаиләләргә (ялгыз яшәүче гражданнарга) дәүләт социаль ярдәме югалган (зыян күргән) торак урын бердәнбер

яшәү урыны булып торган һәм күрсәтелгән гадәттән тыш хәл дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза бирелгән айдан алдагы 12 айдан да соңга калмыйча булган шарт белән күрсәтелә.»;

1.7 пунктта:

«г» пунктчасында «авыр тормыш хәле» сүзләреннән соң «(типик авыр тормыш хәлләренең исемлеге әлеге Нигезләмәнең 10 нчы кушымтасында китерелә)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктның «а», «г» пунктчаларында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән социаль контрактлар бер үк граждан (гражданның гаиләсе) белән елына бер тапкырдан да ешрак төзелми.»;

1.11 пунктның сигезенче абзацында «социаль контракт төзү» сүзләрен «мондый түләүне башкару» сүзләренә алмаштырырга;

1.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.15. Дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, түбәндәге очракларда билгеләнми:

мөрәҗәгать итүче гаиләнең составы, керемнәре һәм аңа (аның гаиләсенә) караган мөлкәте турында тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр тапшырган;

гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача кереме күләмен халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән арттыру;

әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның җан башына уртача кереме социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, айга 20 000 сумнан артыграк була;

гаиләнең (гражданның) «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а« – «г«, «е«, «ж« пунктларында билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән югарырак булуы;

гражданның тулысынча дәүләт тәэминатында булуы;

мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында билгеләнгән вакытта социаль адаптация программасын эшләү өчен килмәве;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль адаптация һәм (яисә) социаль контракт программасының төзелмәве.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының берсе белән төзелгән гамәлдәге социаль контракт булган очракта билгеләнми.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе түбәндәге очракта исәпкә алынмый:

әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән гаиләгә яисә ялгыз яшәүче гражданга социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү;

социаль хезмәт күрсәтүләрне генә күздә тоткан социаль килешү төзү.»;

1.16 пунктның икенче абзацына «, нигезле сәбәпләрсез» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта:

икенче абзацта «мөрәҗәгать итүче катнашында һәм кирәк булганда» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче белән бергә һәм» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең төбәк вәкилләре» сүзләрен «коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән шартлар буенча социаль контракт өзелгән очракта, яңа социаль контракт мондый граждан белән элек төзелгән социаль контрактны өзгән көннән соң 12 айдан да иртәрәк булмаган вакытта төзелергә мөмкин.»;

4.6 пунктның «б» пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе, Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, җирле үзидарә органнары белән берлектә гражданга эшкуарлык эшчәнлеген яисә эшчәнлеген һөнәри керемгә салым түләүче буларак гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтергә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча консультация ярдәме алу өчен гражданны «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә җибәрергә, кирәк булганда шулай ук гражданны «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасы» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыру кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасы оешмалары тарафыннан үткәрелә торган эшкуарлык компетенцияләренә өйрәтү узуга җибәрергә;»;

4.7 пунктның «б» пунктчасында:

дүртенче абзацта «сатып алырга» сүзен «кирәк булганда сатып алырга» сүзләренә алмаштырырга, «матди-җитештерү запасларын,» сүзләреннән соң «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә эшчәнлекнең аерым төрләрен программа белән тәэмин итүгә һәм (яисә) гамәлгә ашыруга лицензия алырга (билгеләнгән түләүнең 10 процентыннан артмый)» сүзләрен өстәргә .

бишенче абзацка «, шулай ук гражданның социаль контракт шартлары нигезендә түләнгән акчаларны максатчан файдаланмау фактын социаль яклауның территориаль органы тарафыннан ачыкланган очракта» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада:

2.2 пунктның өченче абзацында «коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең төбәк вәкилләре» сүзләрен «коммерциягә карамаган микро-кредит компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контракт гамәлдә булган чорда төп чараларны, матди-җитештерү запасларын сатып алырга, программа белән тәэмин итүгә һәм (яисә) эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыруга «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның

4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә лицензия алырга (билгеләнгән түләүнең 10 процентыннан артмаска), индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәти йөкләмәләр кабул итәргә һәм социаль яклауның территориаль органына раслаучы документларны тапшырырга;»;

әлеге Тәртипкә 10 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 21 апрель, 382 нче
карары редакциясендә)

Типик авыр тормыш хәлләре исемлеге

1. Бер һәм аннан да күбрәк гаилә әгъзаларының инвалидлыгы.

2. Күрсәтелгән гадәттән тыш хәл социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза бирелгән айга кадәр 12 айдан да соңга калмыйча булган шартларда табигый бәла-казалар һәм көнкүреш, табигый яисә техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә бердәнбер торак урынын югалту (зарарлау).

3. Гаиләнең барлык хезмәткә сәләтле әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк.

4. Әгәр дәүләт социаль ярдәмен сорап мөрәҗәгать эштән азат ителгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча башкарылса, эшне югалту.

5. Әгәр дәүләт социаль ярдәмен сорап мөрәҗәгать вафат булганнан соң өч айдан да соңга калмыйча башкарылса, якыннарының (ата-ананың, хатынның (иренең) һәм балаларның) үлеме.

6. 18 яшькә кадәрге инвалид бала булган яисә балачактан I төркем инвалид, яисә I төркем инвалид, яисә дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими чит тәрбиягә мохтаҗ карт кешеләр булган якын туганын (ата-анасын, хатынын (ирен), баласын) карау.

7. Әгәр дәүләт социаль ярдәме сорап мөрәҗәгать иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча башкарылса, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү.

8. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында урын булмаганда, баланы ул өч яшькә җиткәнчегә кадәр карап торуны бердәнбер ата-ана (законлы вәкил) тарафыннан гамәлгә ашыру.

9. Ата-аналарның берсе эшкә урнаштырылган шарт белән ул зур иждивение йөкләнешенә бәйле балалы гаиләнең кеше башына уртача кереме халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк.

---